ГЛАВА СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11. 2025 ел. Иске Тәрбит авылы № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кайбыч муниципаль районының Иске Тэрбит торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында .

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тэрбит авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2025 елның 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Иске Тәрбит авылы ,Үзәк урамы, 25 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.
2. 2025 елның 25 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Иске Тәрбит авылы , Уральская урамы, 6 нчы йорт янныда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.
3. 2025 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Иске Тәрбит авылы МФЦ бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының эченче этабын*** билгеләргә.
4. 2025 елның 26 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Иске Тәрбит авылы мәктэп бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дуртенче этабын*** билгеләргә.
5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлегенең Иске Тәрбит авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару

буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

- торак пункт чиклэрендэ гомуми файдаланудагы жирле эһэмияттэге автомобиль юлларын тэзу, ремонтлау, карап тору;

- су белэн тээмин иту чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белэн тэемин иту һэм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һэм башка инженерлык корылмаларын проектлау, тэзу һэм ремонтлау;

- урамнарны яктырту челтэрлэрен, трансформатор һэм алар янындагы мэйданчыкларны, булу пунктларын һэм электр элемтэлэрен тэемин иту һэм электр энергиясен урнаштыру эчен билгелэнгэн башка мэйданчыкларны ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тэрбит авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

“Риза” “Каршы”

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://styaberdin-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Иске Тэрбит авыл җирлеге Башлыгы В.Г. Тимофеев